| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 февраль г.Казань № 88

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 19 февраль, 88 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1205 нче; 2022 ел, 14 февраль, 128 нче; 2022 ел, 1 август, 744 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1499 нчы, 2023 ел, 20 апрель, 499 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктта:

өченче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацка «мөһер белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «(булганда)» сүзен өстәргә;

унынчы абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

унберенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

уникенче абзацка «мөһер белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

унөченче абзацка «мөһер белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

уналтынчы абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

унсигезенче абзацка «мөһер белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин